РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«31» июль 2019 ел Олы Кайбыч авылы № 176

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль-шәхси партнерлык турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

2015 елның 13 июлендә чыккан 224-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль-шәхси партнерлык, дәүләт-шәхси партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турындагы» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Кайбыч муниципаль районы Советының 2016 елның 25 июлендә чыккан 46 номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль-шәхси партнерлык турында Нигезләмәне раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль-шәхси партнерлык турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.3. пунктының 1 подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) юридик яктан билгеле бер срокка рәсмиләштерелгән һәм бер яктан гәвами партнерның, икенче яктан шәхси партнерның хезмәттәшлек рискларын бүлешүгә корылган, дәүләт-шәхси партнерлыгы, муниципаль-шәхси партнерлык килешүенә нгезләнеп гамәлгә ашырыла торган, Федераль закон белән билгеләнгәнчә икътисадка шәхси инвестицияләр тарту, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары товарлар, хезмәт, хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын үстерү максатында ресурсларны кушуга нигезләнгән дәүләт-шәхси партнерлыгы, муниципаль-шәхси партнерлык»;

1.3 пунктының 2 подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) муниципаль-шәхси партнерлык турында, дәүләт-шәхси партнерлык турында килешү (алга таба - килешү) –гәвами партнер һәм шәхси партнер арасында әлеге Федераль законда билгеләнгән шартлар тәртибендә өч елдан да ким булмаган срокка төзелгән гражданлык –хокукый шартнамәсе»;

1.4. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Муниципаль-шәхси партнерлык түбәндәге принципларга нигезләнә:

1) дәүләт сере булган һәм башка закон белән саклана торган мәгълүматтан кала, дәүләт-шәхси партнерлык турындагы мәгълүматның ачыклыгы һәм аңлаешлылыгы;

2) конкуренцияне тәэмин итү;

3) дискриминация булмау, килешү якларының закон каршында тигез хокуклы булуы;

4) килешү якларының килешү буенча вазыйфаларын тиешенчә үтәве;

5) килешү яклары арасында рисклар һәм вазыйфаларның тигез бүленүе;

6) килешү төзүнең ирекле лег е»;

3.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Муниципаль-шәхси партнерлык килешүе объектлары булып түбәндәгеләр тора:

1) шәхси автомобиль юллары яки шәхси автомобиль юллары участоклары, күперләр, саклагыч юл корылмалары, ясалма юл корылмалары, җитештерү объектлары (автомобиль юллары торышы капиталь ремонтында һәм ремонтында кулланыла торган объектлар), автомобиль юллары элементларын төзекләндерү, түләү алу каралган объектлар (шул исәптән түләү алу пунктлары), юл сервисы объектлары;

2) метрополитеннан кала гомуми кулланылыш транспорты;

3) тимер юл транспорты объектлары;

4) труба үткәрү транспорты объектлары;

5) диңгез портлары, елга портлары, махсуслаштырылган портлары, аларның инфраструктура объектлары, шул исәптән ясалма җир кишәрлекләре, порт гидротехник корылмалары, федераль милектә булырга мөмкин булган диңгез порты инфраструктурасы объектларыннан кала, шәхси милекә бирелми;

6) диңгез судлары һәм елга судлары, кушма йөзү судлары (елга - диңгез), шулай ук бозватуны, гидрографик, фәнни-тикшеренү эшчәнлеге, паром хезмәте, йөзмә һәм коры докларны гамәлгә ашыручы судлар, Россия Федерациясе канунчылыгы нигезендә дәүләт милкендә булган объектлардан кала, шәхси милекә бирелми;

7) һава судлары, аэродромнар, аэропортлар, техник чаралар һәм башка һава судлары очышын тәэмин итүгә каралаган чаралар, дәүләт авиациясе милкенә яки һава хәрәкәтен оештыруның бердәм системасына караган объектлардан кала;

8) электр энергииясен җитештерү, тапшыру һәм бүлү объектлары;

9) гидротехник корылмалар, стационар һәм (яки) йөзмә платформалар, ясалма утраулар;

10) су асты һәм җир өсте техник корылмалары, чыгу урыннары, элемтә корылмалары, элемтә линияләре һәм коммуникацияләр, элемтә һәм коммуникацияләрнең башка линияле объектлар;

11) сәламәтлек саклау объектлары, шул исәптән сәламәтлек саклау өлкәсендә санатор-курорт дәвалануы алу һәм башка эшчәнлек объектлары;

12) мәгариф, мәдәният, спорт объектлары, гражданнарның ялын һәм туризмны оештыруда кулланыла торган объектлар, халыкка социаль хезмәт күрсәтүнең башка объектлары;

13) каты коммуналь калдыкларны эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру һәм урнаштыру гамәлгә ашырыла торган объектлар;

14) территорияләрне төзекләндерү, шул исәптән аларны яктырту объектлары;

15) дәүләт мелиоратив системаларыннан кала мелиоратив системалар һәм аларның инженерлык инфраструктурасы объектлары;

16) Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән критериеләр белән билгеләнгән җитештерү объектлары, беренчел һәм (яки) икенчел (сәнәгать) эшкәртү, авыл хуҗалыгы продукциясен саклау объектлары;

17) аучылык инфраструктурасы объектлары;

18) сәнәгать продукциясе җитештерүгә каралган һәм (яки) сәнәгать өлкәсендә башка эшчәнлекне гамәлгә ашыруга каралган мөлкәти комплекслар;

19) электрон исәпләү машиналары өчен программалар (ЭВМ өчен программалар), мәгълүмат базалары, информацион системалар (шул исәптән дәүләт мәгълүматый системалары) һәм (яки) «Интернет» мәгълүматый-телекоммуникацион челтәрендәге сайтлар яки башка мәгълүматый-телекоммуникацион челтәрләрдәге составына ЭВМ өчен программалар һәм (яки) мәгълүмат базалары, я булмаса әлеге объектлар күплеге (алга таба- мәгълүматый технология объектлары), яисә шундый бер яки берничә объект белән технологик бәйләнгән һәм аларның эшләвен тәэмин итү өчен килешү белән каралган башка эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен каралган мәгълүматый технология объектлары һәм мөлкәт (алга таба - мәгълүматый технологияләр объектлары эшләвен тәэмин итүче техник чаралар);

20) зданиеләр яки биналар өлешләре күплеге, хәрәкәт итүче милекне бердәм билгеләү белән гомумиләштерелгән, мәгълүматый технологияләр объектлары белән технологик бәйләнгән, һәм мәгълүматны ЭВМ өчен программалар һәм мәгълүмат базалары кулланып, саклау, эшкәртү, кабул итү, тапшыру, аны куллану һәм тарату мөмкинлеге программалырын автоматлаштыру (мәгълүматлар эшкәртү үзәкләре)».

7.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.1. Килешүнең мәҗбүри элементлары булып түбәндәгеләр тора:

1) килешүнең шәхси партнеры тарафыннан төзелеш һәм (яки) реконструкция (алга таба – барлыкка китерү);

2) килешү объекты төзүне соглашения финанслауны тулысынча яки өлешчә гамәлгә ашыру;

3) шәхси партнер тарафыннан килешү объектын эксплуатацияләү һәм (яки) техник карауны гамәлгә ашыру;

4) Федераль закон нигезендә килешү объектына обременение шарты булганда, шәхси партнерда килешү объектына карата шәхси милекчелек хокукы барлыкка килү».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы

Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге рәсми урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми бастырылган көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы Башлыгы,
Совет Рәисе А.И. Рәхмәтуллин